**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 5444**
**22.10.2020**

Башкарма комитетның эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өлкәсендәге аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында

«Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
2018 елның 3 декабрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырылган «Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 7122 номерлы Башкарма комитет карары;

2) «Челнинские известия» газетасында 2019 елның 19 августының 62 санында басылып чыккан; 2019 елның 21 августында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырылган «Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 7122 номерлы Башкарма комитет карары белән расланган «Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 19 августындагы 4267 номерлы Башкарма комитет карары;

3) «Челнинские известия» газетасында 2020 елның 11 мартының 18 санында басылып чыккан; 2020 елның 11 мартында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырылган

«Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 мартындагы 1077 номерлы Башкарма комитет карары;

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет<br>
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов